**Раслыйм** ____________________

«Ватаным Татарстан» газетасы
баш мөхәррире Г.И. Сабирова

20 гыйнвар, 2022 ел

# «БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!»
# РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ВИДЕОПРОЕКТЛАР БӘЙГЕСЕ
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу нигезләмә «Безгә килеп күрегез!» (алга таба – Бәйге) республикакүләм видеопроектлар бәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Бәйге авылда, шәһәрдә, бистәдә, район үзәгендә бүгенге яшәешне тасвирлауны, көндәлек тормышта туган телнең кулланышын, гореф-гадәт, милли үзенчәлекләрнең сакланышын чагылдыруны күздә тота.

1.3. Бәйгенең бурычлары:

– туган телгә мәхәббәт тәрбияләү;

– гореф-гадәт, милли йолалар, үзенчәлекләрне саклау һәм үстерү;

– милли үзаңны үстерү;

– «Ватаным Татарстан» газетасының аудиториясен арттыру.

1.4. Бәйгедә катнашу ирекле һәм түләүсез.

1.5. Бәйгенең рәсми теле – татар теле. Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе.

1.6. Бәйгене уздыру турында барлык мәгълүмат «Ватаным Татарстан» газетасы сайтында бастырыла: www.vatantat.ru.

## 2. Бәйгедә катнашучылар

2.1. Бәйге өч төркемдә уздырыла:

– 10–17 яшьлекләр;

– 18–34 яшьтәгеләр;

– 35 яшьтәге һәм өлкәнрәкләр.

Бәйге эшенең авторы (катнашучы) берәү яки авторлык коллективы (10 кешедән артмаска тиеш) була ала.

2.2. Бер катнашучы яки бер коллектив бары тик бер эш җибәрә ала.

**3. Бәйгене уздыру тәртибе һәм вакыты**

3.1. Бәйге 2023 елның 23 гыйнварыннан алып 2023 елның 10 июленә кадәр үткәрелә.

3.2. Катнашуга гариза һәм эшләр 2023 елның 23 гыйнварыннан 10 маена кадәр кабул ителә. Гариза үрнәге беркетелгән (Кушымта).

3.3. Иң яхшы материаллар өчен тавыш бирү 2023 елның 1 февраленнән 31 маена кадәр дәвам итәчәк. Тавыш бирү этаплап башкарылачак.

3.4. Җиңүчеләр исемлеген бастырып чыгару – 2023 елның 10 июненә кадәр.

3.5. Бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү – 2022 елның 10 июленә кадәр.

**4. Бәйгедә катнашу кагыйдәләре**

4.1. Бәйгедә авыл, шәһәр, бистә, район үзәгенең бүгенге яшәешен: җирлекнең көндәлек тормышын, кызыклы гадәтләр, үзенчәлекле кешеләр, йолалар, бәйрәмнәрен тасвирлаган видеороликлар яки видеорепортажлар катнаша. Видеоролик/репортаж татар телендә булырга һәм «Көндәлек тормышта татар теле ничек кулланыла?» дигән сорауга җавап бирергә тиеш.

4.2. Иҗади эшләргә таләпләр:

– видеоязманың хронометражы: **5 минутка кадәр**;

– видеоязма **горизонталь** рәвештә төшерелгән булырга тиеш;

– материал теләсә нинди видеокамера, шул исәптән смартфон камераларына да төшерелергә мөмкин;

– видеоязмада аудио һәм визуаль материал чиста, сыйфатлы булырга тиеш;

– анимация, фотосурәт һәм башка мультимедиа алымнарын кулланырга рөхсәт ителә;

– кадрда логотиплар, сәүдә маркалары, патентланган дизайн элементлары, реклама һәм башка төр шәхси мәгълүмат булырга тиеш түгел;

– техник таләпләр: минималь рөхсәт ителгән күләм – 640x480 (720x480) пикс;

максималь рөхсәт ителгән күләм – 1920x1080 (1920x1080) пикс;

– видеороликны монтажлаганда һәм төшергәндә махсус программалар һәм инструментлар куллану – автор һәм иҗат коллективы ихтыярында;

– автор видеоязманың жанрын үзе билгели (интервью, репортаж, документаль видеоклип һ.б.);

– видеода слайд-шоу рәвешендә генә фотолар куллану тыела.

4.4. Видеоролик яки видеорепортаж редакциягә Гариза (Кушымта) белән җибәрелә. Видео видеоплатформага (YouTube) яки социаль челтәрләргә («ВКонтакте») куелган очракта карау өчен ачык булырга тиеш, бәйгегә шуңа сылтама җибәрелә. Бәйге игълан ителгән вакытка кадәр (2023 елның 23 гыйнварына кадәр) куелган яки әлеге эшнең бәйгедә катнашу өчен төшерелгән булуы күрсәтелмәгән эшләр кабул ителми.

4.5. Конкурс эшләре түбәндәге критерийларга нигезләнеп бәяләнәчәк:

– конкурс нигезләмәсенә туры килү;

– татар теленең кулланылышы;

– иҗадилык һәм оригинальлек;

– эчтәлек (сюжет сызыгының мантыйклы, мәгълүматлы булуы, әхлакый кыйммәте, РФ һәм ТР законнарына каршы килмәве);

– сыйфат (техник башкарылыш (тавыш, монтаж, бизәлеш) һәм эчтәлек;

– эмоциональ тәэсир итүчәнлек.

4.6. Бәйгедә катнашучы нигезләмәнең 3.2 пунктында каралган срокларда катнашу өчен Гариза тутыра һәм иҗади эшен редакциянең электрон адресына җибәрә: konkurs_vt@mail.ru. Хат темасында «Безгә килеп күрегез!» конкурсына» дип күрсәтү мәҗбүри.

**5. Бәйгегә йомгак ясау һәм җиңүчеләрне билгеләү**

5.1. **Гран-при** иясе, **3 җиңүче** һәм **кызыксындыру бүләкләре ияләре** vatantat.ru сайтында 2023 елның 1 февраленнән 31 маена кадәр тавыш бирү юлы белән сайланачак.

5.2. Җиңүчеләрне билгеләү берничә этаптан торачак.

1. Атна саен газетабызның онлайн мәйданчыкларында (vatantat.ru сайты һәм «ВКонтакте» социаль челтәрендәге махсус төркем) конкурста катнашучы видеоязмалар өчен тавыш бирү оештырылачак. Тавыш бирү башлану турында

хәбәр онлайн мәйданчыкларда һәм газетада махсус QR-код белән урнаштырылачак.

2. Конкурска юлланган видеоязмалар төркемнәргә бүленә. Беренче атнада онлайн мәйданчыкларда иң беренче булып килгән 10 эш урнаштырыла. Аларга тавыш бирү өчен төгәл бер атна вакыт билгеләнә. Икенче атнада чираттагы видеоязмалар өчен тавыш биреп булачак. Шулай итеп, иң күп тавыш җыюга карап, һәр атна ахырында бер җиңүче ачыкланачак.

3. Һәр атна җиңүчесе ярымфиналга уза. Бу этапка узучылар өчен тагын бер кат тавыш бирү оештырылачак.

4. Тавыш бирү этапларының барлык нәтиҗәләрен исәпкә алып, жюри вәкилләре карар чыгарачак. Җиңүчеләрне билгеләгәндә, барлык критерийлар белән беррәттән, тавыш бирү нәтиҗәләре, активлык исәпкә алыначак.

5.3. Җиңүчеләргә бүләкләр:

– Гран-при – **50000** сум күләменә акчалата премия.

– «10–17 яшьлекләр» номинациясендә җиңүчегә – 25000 сум премия, 15000 сумлык ике кызыксындыру премиясе;

– «18–34 яшьлекләр» номинациясендә җиңүчегә – 25000 сум премия, 15000 сумлык ике кызыксындыру премиясе;

– «35 яшь һәм өлкәнрәкләр» номинациясендә җиңүчегә – 25000 сум премия, 15000 сумлык ике кызыксындыру премиясе.

5.4. Бәйгене үткәрү тәртибе һәм аның нәтиҗәләренә апелляция бирү каралмаган.

5.5. Җиңүчеләрләрне бүләкләү датасы һәм урыны өстәмә рәвештә www.vatantat.ru сайтында һәм газетада игълан ителәчәк. Оештыручылар Гран-прины җиңүче видеоязмада тасвирланган җирлеккә барып тапшырачак.

**6. Авторлык хокуклары**

6.1. Катнашучы, Гаризаны юллап, видеоматериалны оештыручы тарафыннан файдалануга рөхсәтен бирә.

6.2. Оештыручы материалны тавыш бирү өчен vatantat.ru сайтында, «Ватаным Татарстан» газетасының социаль челтәрләрендә урнаштыра һәм кабул итеп алган

көннән башлап, конкурс тәмамланганчы (2023 елның 10 июленә кадәр) файдалана.

6.3. Оештыручы әлеге видеоматериал белән жюри әгъзаларын таныштырырга хокуклы.

6.4. Оештыручы видеоматериалларны үзгәртми, төзәтмәләр кертми. Конкурс тәмамлангач, оештыручы әлеге видеоматериалларны vatantat.ru сайтыннан һәм онлайн тавыш бирү мәйданчыкларыннан алып куя.

6.5. Бәйгедә катнашырга теләүченең эшен оештыручыларга җибәрүе әлеге Нигезләмә белән тулысынча килешүен һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон (Федеральный закон от 27.07.2006 №152-ФЗ «О персональных данных») нигезендә шәхси мәгълүматларын кулланырга рөхсәт бирүен раслый.

# Гариза

| | |
|---|---|
| **Ф.И.О.:** | |
| **Яшәү урыны:** | |
| **Телефон, электрон почта, адрес:** | |
| **Номинация (яшь категориясе):** | |
| **Видеоролик яки видеорепортажга сылтама (интернетта урнаштырылган очракта):** | |
| **Иҗади эшнең тавсирламасы:** | |